
# Гомәр Бәшир улы Бәширов

**Татарстанның халык язучысы, фольклорчы.**

(1901 – 1999)







# Биография



1982 ел, Яңа Сала. Туган нигезе урынында төзелгән китапханә янында

Гомәр Бәшир улы Бәширов 1901 елның 7гыйнварында элеккеге Арча волостеның Яңа Сала авылында(хәзер Татарстанның Арча районы) крестьян гаиләсендә туа.

Җиде яшендә аны остабикәгә, аннан авыл мәдрәсәсенә бирәләр, шунда ул укырга-язарга өйрәнә, арифметика, география кебек дөньяви фәннәрдән дә беркадәр мәгълүмат ала. Соңрак авыл мәктәбендә укый.

Унөч яшьлек Гомәрне чит авылда кием тегеп йөрүче бер абзыйга өйрәнчек итеп бирәләр.

1919 елда аны Арча волостеның Урта Бирәзә авылына беренче баскыч мәктәп укытучысы итеп билгелиләр.

1920 елның маенда ул Кызыл армиясе сафларына алына, Гражданнар сугышында катнаша.

1924 елда гаскәри хезмәттән бушагач, Г. Бәширов Эчке эшләр Халык Комиссариатының Казандагы бер еллык махсус мәктәбенә укырга керә, аны тәмамлагач, дүрт елдан артык Арча кантоны милиция органнарында эшли.

1929—1932 елларда исә Балтачта һәм Дөбъязда халык тикшерүчесе, халык судьясы хезмәтләрен башкара. 1932 елның җәендә ул республика газетасы «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») редакциясенә күчерелә.

1934—1936 елларда Г. Бәширов Казандагы марксизм-ленинизм институтының аспирантурага хәзерлек бүлегенда укый, аны тәмамлагач, институтның төп курсына кабул ителә, ләкин, авырып китү сәбәпле, укуын дәвам итә алмый. 1936 елның ахырыннан алып ул Татарстан Язучылары союзы органы «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә җаваплы секретарь, аннары, 1938 елның июненнән, Татарстан дәүләт нәшриятында (Татгосиздатта) матур әдәбият секторы редакторы булып эшли.

1931 елда Мәскәүдә «Ударниклар» журналында «Канлы бармаклар» исемле беренче хикәясе басыла. 1934 елда Г.Бәшировның «Соңгы сугыш» дигән хикәясе китап булып басыла.

1937 елда бастырып чыгарган «Сиваш» повесте аны таланлы язучы буларак таныта.

Г. Бәширов – 1938 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г.Бәширов яңадан «Совет әдәбияты» журналында җаваплы редактор булып эшли, ә 1942 елда аңа Татарстан радиокомитетының баш редакторы һәм председатель урынбасары вазифасын йөклиләр.

1948 елда сугыш елларында языла башлаган «Намус» романы языла бетеп дөнья күрә.

1953 елда ул Татарстан Язучылар союзының идарә председателе итеп сайлана һәм 1958 елга кадәр шул җаваплы вазифаны башкара, аннары, 1958 елдан башлап, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателенең Федерациядәге милли әдәбиятлар буенча урынбасары була.

1951 - 1954 елларда Татарстан АССР Югары советы депутаты. 1953 – 1962 елларда СССР Югары Советы депутаты (2 тапкыр). 1957 - 1959 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты члены булып тора.

1960 еллар башыннан Г. Бәширов — профессиональ язучы.

Әдипнең алтмышынчы-җитмешенче еллардагы иҗатыннан аеруча ике әсәре игътибарга лаек: «Туган ягым – яшел бишек» повесте (1967) һәм «Җидегән чишмә» романы (1977).

Г. Бәширов татар халык иҗатын җыюга, аны тикшерергә дә күп көч куйган язучы. Халык иҗаты әсәрләрен ул бала чактан ук җыя башлап, кырыгынчы еллар ахырында аларны пропагандаларга керешә. Аның үзе җыйган, язып алган, әдәби эшкәрткән халык әкиятләре, җырлары, мәзәкләре, җыентыкларга тупланып, татар телендә генә түгел, илебездәге башка милли телләргә дә, чит ил телләренә дә тәрҗемә ителеп басылалар.

1984 елда «Казан утлары» журналында (3, 4 саннар) әдипнең «Көзге ачы җилләрдә» исемле яңа документаль повесть-истәлеге басылып чыкты.

# Гаиләсе.



Гомәр Бәширов тормыш иптәше Кәримә белән исә Кенәрдә эшләгәндә таныша. Озак та үтми, өйләнешеп тә куялар. Аның уңышлары, әдәбияттагы казанышларында Кәримәнең өлеше зур була.

Гомәр Бәширов гаиләсендә ике бала үсә. Олы кызлары Лилия, университет тәмам-лагач, юллама белән Арча ягына юл тота. Шунда язмыш аны Мөхәммәт Мәһдиев белән очраштыра, шунда ул аның тормыш иптәше булып куя. Оныклары Гәүһәр Хәсәнова да әтисе, бабасы мирасын барлау, саклау, аны халыкка таныту буенча шактый эшли. ниверситетны тәмамлагач, Төркмәнстанның Красноводск аэропортында инженер-метеоролог, аннары Казандагы хәрби заводта инженер булып эшли. Соңрак Мәскәүнең Яңалыклар Мәгълүмат Агентлыгының (АПН) Идел буе төбәге фотохәбәрчесе була. 1985 елда Татарстан китап нәшриятына килә. Әтисе вафатыннан соң, көндәлекләрен бастырып чыгара. Гомәр аганың оныгы Наиләгә дә һөнәр сайлаганда бабасы йогынты ясагандыр, ул бүгенге көндә филология фәннәре кандидаты, доцент. Казан федераль университеты, Казан дәүләт консерваториясендә инглиз һәм итальян телләрен укыта.



Гомәр Бәширов улы Зөфәр белән.




Зөфәр Бәширов әтисенең портреты белән.

# Истәлек фотолар








Гомәр Бәширов Хасан Туфан белән.



Уйланулар...



Гомәр Бәширов Сәйфи Кудаш белән 1966 ел.





# Исемнре, бүләкләре


- Г. Бәширов - 1938 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.
- 1951 ел - Гомәр Бәширов «Намус» романы өчен СССР Дәүләт премиясенә лаек була.
- 1957 елда – Ленин ордены, 1950, 1962 елларда - Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары(ике тапкыр), 1968 елда - Кызыл Йолдыз ордены, 1971 елда - Октябрь Революциясе медале, 1981 елда Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнә.
- 1986 ел - «Татарстанның халык язучысы» исеме бирелә.
- 1993 ел - Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләге бирелә.
- 1996 ел - Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.




**Әдип 1999 елның 7 маенда Казанда вафат була, Яңа бистә зиратына җирләнә.**


# Төп басма китаплары


Мең дә бер мәзәк / мәзәкләрне җыючы һәм әдәби эшкәртүче Г.Бәширов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.
Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе: хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968.
Намус: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.
Туган ягым – яшел бишек: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973.
Бүген дә, иртәгә дә: әдәби тәнкыйть, публицистика, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.
Сиваш: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.
Җидегән чишмә: роман. – 1 китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.
Җидегән чишмә: роман. – 2 китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.
Әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981–1984.
Тормыш юлында: повесть-истәлек, мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.
И язмыш, язмыш: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.
Бибек нигә елый: хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.
Гыйбрәт: тәмамланмаган роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 367 б. – 5000 д.
Сайланма әсәрләр: 5 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
Туган ягым – яшел бишек: повесть. – Өфә: Китап, 2001. (Башкорт телендә.)
Кетеки тел бистәләре: мәзәкләр / төз. Г.Бәширов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.
Семь родников: роман / пер. с татар. Л.Лебедевой. – М.: Современник, 1986.
Честь: роман / пер. с татар. Р.Фаизовой. – М.: Сов. Россия, 1988.




荣誉
NAFISSE
Roman einer Liebe · Von G. Baschirow
НОМУС
ЧЕСТ
GUMER BAŠIROV
ČEST


ГОМӘР БӘШИРОВ
ЧЕСТЬ
СУРОВОЕ ИСПЫТАНИЕ
ГУСАК, ГУСЫНЯ И ДЮЖИНА ГУСЯТ


ҒУМӘР
БӘШИРОВ
НАМУС
Бакы — Ушагҝәнҹнәшр — 1952


Татар прозасы
Гомәр
БӘШИРОВ
Туган ягым —
яшел бишек

# Туган авылы Яңасалада Г. Бәширов истәлекләре.









